Шәһри Казан

ҖОМГА, 11 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
№ 4 (5182)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КӨН АВАЗЫ

Татарстанның Мөслим районында полиция капитаны, эш урыныннан файдаланып, җинаять кылуда гаепләнә. Ул район ЮХИДИ идарәсе җитәкчесенең кабинетыннан 1,5 елга машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән бер ир-атның машина йөртү таныклыгын урлап чыккан. Соңыннан 25 мең сум акча хисабына аны хуҗасына тапшырган. Караклыкта тотылган инспекторны эшеннән азат иткәннәр.

***

Американың Айова штаты Югары суды үзенчәлекле карар кабул иткән. Хәзер биредә җитәкчесенең гаилә тормышын бозу куркынычы тудыра торган артык чибәр ханым һәм туташларны, берни дә аңлатып тормастан, эшләреннән азат итәргә мөмкиннәр. Кешене шул рәвешле эштән җибәрү гаделлеккә туры килмәсә дә, бу әлеге штатта кабул ителгән хокукый нормаларны бозмый икән.

***

Руль артында классик музыка тыңлауның зыяны зур булырга мөмкин. Британия галимнәре классик музыка руль артында баручыларның игътибарын һәм реакциясен киметә дигән фикергә килгәннәр. Бетховенның «5 нче симфония»се иң куркыныч музыка дип табылган. Бах һәм Штраус әсәрләре дә куркыныч исемлеккә керә. Ә менә рок һәм поп музыкасын рәхәтләнеп тыңлап барырга була.

***

Лондон метросы – дөньядагы иң борынгы метро. Аның беренче линиясе ачылганга 150 ел тулды. 1863 елның 10 гыйнварында, ягъни аның ачылыш көнендә метродан 30 мең кеше файдаланган булган. Хәзер Лондон метросы елына 1 миллиард пассажирны йөртә.

МАШИНАҢ НӘРСӘ «ЭЧӘ»: БЕНЗИНМЫ, СУМЫ?

Юлда машина күп, дип зарланырга яратабыз. Аның ягулык салу станцияләре дә яңгырдан соң чыккан гөмбә кебек артып кына тора. Бүген Татарстанда барлыгы 994 АЗС исәпләнә. Тик менә бөтенесендә дә сыйфатлы ягулык тәкъдим ителәме икән соң?

СЫЙФАТ

Сөембикә БИЛАЛОВА

ТР Хөкүмәте йортында узган брифингта республикада ягулык-энергетика чыганакларын нәтиҗәле файдалану идарәсе җитәкчесе Роберт Гыйләҗиев мотор ягулыгының сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырды. Мониторинг барышында 511 станциядән 1092 проба алынган. Нәтиҗәдә, һәр 20 нче очракта ГОСТ таләпләре үтәлмәгәнлеге ачыкланган. Бензин дип атап та булмаган сыйфатсыз сыеклыкка кирәгеннән артык күкерт кушыла икән. Кайбер станцияләрдә ягулыктагы күкертнең күләме тиешледән 700 тапкырга артыграк булып чыккан. Ә АЗС хезмәткәре юләр түгел: «Евро-3» класслы ягулыкны «Евро-5» дип сата ул. «Мондый ягулык салган машинаңны ярты сәгатькә калдырып торсаң, кабыза алмаячаксың инде. Чөнки 22 градус салкында гына катарга тиешле ягулык 12 градуста ук куера башлый», – дип, проблеманың асылын аңлатты Р. Гыйләҗиев.

Кимчелек табылган АЗСларның күбесе – шәхси һәм Казаннан читтә урнашкан станцияләр. Үзлегеннән тикшереп карау яисә бензин беткән саен зур шәһәргә чыгып чабу мөмкинлеге булмагач, машина йөртүченең шикле ягулыкны салмый хәле юк. Ә сорау бар икән, тәкъдимнең артасы билгеле. Тикшерүдән күренгәнчә, «Татнефть», «Татнефтепродукт», «ТАИФ-НК», «Карсар» ЖЧЖ һәм «ЛУКОЙЛ» кебек эре ягулык салу станцияләрендә барысы да тәртиптә.

Роберт Гыйләҗиев фикеренчә, республикага меңгә якын ягулык салу станциясенең кирәге юк, өч йөзе дә бик җиткән. Аларны дөрес ераклыкта урнаштырырга гына кирәк. Ике АЗС арасы 15-20 километр булырга тиеш, ә бездә – 200-400 метр саен станция.

Ә ягулыкның бәясенә килгәндә, Идел буе федераль округының калган төбәкләре белән чагыштырганда, бездәге бәяләр иң түбәне икән. 2012 ел нәтиҗәләрен карасак, Идел буенда АИ-92ле бензин уртача 27,68 (Татарстанда – 27,1), АИ-95лесе – 30,43 (29,9), дизель ягулыгы 31,29 (31,40) сум булган. Бәйрәмнәрдән соң, АИ-92ле бензин Татарстанда ун тиенгә арзанайган, Идел буенда исә, киресенчә, күтәрелгән. Гомумән алганда, ел дәвамында бөтен төр ягулыкка да бәяләр 2,5-3 сумга артыр дип фаразлана.

БАШКАЛАДА

Яшьләр театрында яңа җитәкче

Г.КАРИЕВ исемендәге Казан дәүләт яшь тамашачы театрына яңа директор билгеләнде. Ул – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ярмиев Мансур Зиннур улы. М.Ярмиев 1964 елда Саба районының Явлаштау авылында туган, Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетында белем алган.

Кем курыкмый, шул килсен

«КАЗАНРИНГ» автодромында 13 гыйнвар көнне Ралли-Спринт буенча 2 нче этап ярышлары була. Беренче этап 15 декабрьдә төнлә узган иде. Анысында иң яхшы күрсәткечләргә Максим Доронкин һәм Сергей Галкин ирештеләр. Бусында яңалык – 650 метр озынлыгындагы боз трассасыннан бару. Ярышларда теләсә нинди автомобиле белән теләсә кем катнаша ала, бирегә керү ирекле. Теркәлү 10.00 сәгатьтә, ә ярышлар 12.30 минутта башлана.

Музыка ул — җанга ял

БИШ меңле тираж белән басылган Татарстан композиторлары антологиясе Казанга кайтты. Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР Дәүләт симфоник оркестры аны тәкъдим итәргә җыена. Билгеле булганча, ул август аенда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында яздырылган иде. Антология 23 гыйнварда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында тәкъдим ителәчәк. Татарстан композиторлары әсәрләре яздырылган дисклар кичә кунакларына бүләк ителәчәк.

Дуслык булса, җиңәрбез

Г.КАМАЛ исемендәге Татар дәүләт академия театрының кече залында 12 һәм 13 гыйнвар көннәрендә Ульрих Хубаның «У ковчега в восемь» пьесасы буенча куелган спектакль күрсәтелә. Ул – театр студиясенә йөрүчеләрнең иҗат җимеше. Студия исә көз көне генә Марсель Сәлимҗанов исемендәге актерлар йорты базасында оешкан иде. Дуслык темасын яктырткан спектакльләр 17.00 сәгатьтә башлана.

ФОТОХӘБӘР

Камилла. Новосибирск шәһәре.

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

Яшь талантлар чыгыш ясады

КАЗАНДА «Рождественская сказка» II Бөтенроссия эстрада иҗаты фестиваль-конкурсы булды.

«Виктория» балалар иҗаты фонды башлангычы белән оештырылган фестиваль-конкурста вокал һәм хореография жанрларында шөгыльләнүче коллективлар һәм солистлар, балалар мода театрлары, цирк төркемнәре үз осталыкларын күрсәтте.

«Шәһри Казан»да бергә кайнык! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Бер-беребездән өйрәник

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов Малайзия башкаласының транспорт системасы белән танышты.

«Малайзия башкаласының җәмәгать транспорты эшен оештыруы яхшы үрнәк булып тора, аны Казан белгечләренә өйрәнергә кирәк», – дип белдерде ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Малайзия башкаласының транспорт системасын тәкъдир итү барышында. KLRapid өч аерым транспорт системасын мирас итеп алган – ике метро линиясе һәм автобус челтәре – һәм хәзер аларның бергә эшләвенә зур игътибар бирә. Бердәм диспетчер хезмәте, пассажирларның күләменә, юлдагы вазгыятькә һәм башка факторларга бәйле рәвештә, җәмәгать транспорты графигын оператив үзгәртергә мөмкинлек бирә. ТР Президенты, KLRapid компаниясен нәтиҗәле транспорт системасын булдыру тәҗрибәсен өйрәнү өчен, Казаннан киләчәк белгечләрне кабул итүен сорады. Рөстәм Миңнеханов шулай ук Малайзия ягына автобусларда табигый газдан файдалану мөмкинлеген өйрәнергә тәкъдим итте.

Бүләк итәрмен чәчәк бәйләме...

УНИВЕРСИАДА-2013 җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы өчен иң яхшы чәчәк бәйләме проектына бәйгегә гаризалар 20 гыйнварга кадәр кабул ителә.

Бу хакта «Казан-2013» Башкарма дирекциясенең рәсми сайтында хәбәр ителә. Бәйгедә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр катнаша ала. Алар үз көчләрен «Welcome to Kazan» (Уеннар кунаклары өчен чәчәк букеты дизайн-проекты) һәм «Be the champion» (спортчыларны бүләкләү тантаналарында катнашучылар өчен букет дизайн-проекты) номинацияләрендә сынап карый алачак. Өч этапта узачак бәйгенең кагыйдәләре белән тулырак http://kazan2013.ru/ru/news_items/6121 сылтамасы аша кереп танышырга мөмкин.

Юлга чыксаң, белеп тор

ВАСИЛЬЕВО станциясендәге төзекләндерү эшләре шәһәр яны поездлары расписаниесенә үзгәрешләр кертә.

Юлларны төзекләндерү сәбәпле, 15 гыйнварда Васильево станциясе аша узучы шәһәр яны поездлары расписаниесенә үзгәрешләр керә. 6001, 6355 һәм 6365 нче поездлар бу көнне ВРД, Займище, 774 нче км станцияләреннән тукталыш ясамый гына узып китәчәк. 6473/6342 нче Коркачык-Васильево поезды расписаниедән вакытлыча алына.

Күргәзмәдә күренеп кайтсыннар

ТАТАРСТАН делегациясе «Яшел атна-2013» халыкара күргәзмәсендә катнашачак.

17-27 гыйнвар көннәрендә Германия башкаласы кабат авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышларны демонстрацияләү мәйданына әйләнәчәк. Биредә 78 нче тапкыр «Яшел атна-2013» халыкара агросәнәгать күргәзмәсе узачак. Әлеге мәртәбәле күргәзмәдә Татарстанны «Вамин-Татарстан», «Ак Барс» холдинг компаниясе» («Пестречинка»), «Татспиртпром», «Казан май сыгу заводы» ААҖ, «Агросила групп» ЯАҖ («Чаллы-Бройлер»), «Татарстан кулланучылар берлеге», «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ һ.б. предприятиеләр тәкъдим итәчәк. Халыкара күргәзмә программасында сәүдә, урманчылык һәм ландшафт проектлавы продукциясе демонстрациясе, симпозиумнар, семинарлар һәм форумнар урын алачак.

Эшлим дигәнгә эш җитә

ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы чит ил кешеләрен эшкә җәлеп итү буенча мөрәҗәгатьләр кабул итә башлаган.

Министрлык тәкъдим иткән эш урыннары арасында төзелеш һәм торак-коммуналь хезмәтләр өлкәләре өстенлектә. Шул ук вакытта чит ил кешеләрен хезмәткә җәлеп итүнең квота-чиге дә расланган: 2013 елда ул 23,4 меңнән артмаска тиеш. Хәзерге вакытта эш бирүчеләрдән 2014 елга гаризалар кабул ителә һәм 2013 елга шундый хезмәт көче күпме кирәклегенә гариза нигезендә төзәтмәләр кертелә. Документлар исә быел 1 майга кадәр Казан шәһәре, Волгоград ур., 47 нче йорт, 3 нче бүлмә адресы буенча кабул ителә. «Миграция квоталары» автоматлаштырылган мәгълүмат комплексын сәнәгый гамәлгә кертү нәтиҗәсендә, беренчел заявкалар һәм гаризаларны Интернет аша кабул итеп була.

КАЗАН ХӘБӘРЛӘРЕ

Инвалидларга битарафлык күрсәтү — гөнаһ

Казанда гына да 90 меңгә якын инвалид, шул исәптән өлкән яшьтәгеләр, кечкенә балалы хатын-кызлар, хезмәткә вакытлыча яраксызлар яши.

Автор фотосы

ЯШӘЕШ

Дамир БӘДРИЕВ

Татарстанда 2011 елдан башлап «Уңайлы мохит» программасы гамәлгә ашырыла. Ул – беренче чиратта шушы категория кешеләр өчен сөенеч. Казанда узган ел 154 юл чаты инвалидлар өчен җайлаштырылды, метро станцияләрендә сукырлар өчен сиземләү сукмаклары ясалды. Яңага алмаштырылган 486 лифт Брайль шрифтлы һәм катларны аваз белән белдерүче радиоаппаратлы. Җәмәгать транспортындагы 519 автобус арба керү-чыгу өчен махсус механизмлы. Быелның май аена кадәр тагын шундый 159 автобус кайтачак.

Шәһәр башкарма комитетында узган киңәшмәләрдә мэр Илсур Метшин: «Казанда физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә уңайлы мохит тудыруда Мәскәүдән һәм Европа шәһәрләреннән үрнәк алып эшләргә кирәк», – дип, әледән-әле искәртеп тора. Ләкин шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасары Азат Нигъмәтҗанов әйткәнчә, күп кенә предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең «Уңайлы мохит» программасын гамәлгә ашыруда башкарган эшләре «күз буяу» өчен генә. Хәер, яңа тапшырылучы йортларда һәм биналарда, эре сәүдә үзәкләрендә инвалидлар мәнфәгатьләре алдан уйланыла. Тик элегрәк төзелгән йортларга, биналарга, кибетләргә, банкларга һәм һәртөрле учреждениеләргә керү өлешенә өстәп ясалган авыш юлларның күбесе гамәлгә яраксыз. Алардан инвалид, бала арбалы хатын-кыз түгел, сәламәт кеше дә үтә алмый. Авыш юллар йә чиктән тыш текә, йә лабиринт сыман бормалы-сырмалы. Кайбер авыш юлларның нәкъ башлангычына чүп савыты беркетелгән. Тагын бер галәмәт: авыш яки махсус җайлаштырылган юллар кардан чистартылмаган. Мәсәлән, Тукай мәйданындагы җир асты кичүендә бала арбалы хатын-кызлар чарасызлыктан үзләре еларга әзер.

Бәләкәчләр өчен түләү артты

2013 елның 1 гыйнварыннан яшь балалы гаиләләргә бирелә торган барлык төр пособиеләргә дә индексация ясалды.

ЯҢАЛЫК

Мәүлитҗан ӘХМӘТҖАНОВ

РФ Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе идарәчесе Рамил Гайзатуллин хәбәр итүенчә, хәзер баланы яшь ярымга кадәр тәрбияләү өчен бирелә торган айлык пособиенең минималь күләме беренче балага – 2453 сум 93 тиен, икенче һәм аннан соң туган балаларга 4907 сум 85 тиен тәшкил итә. Узган ел бу пособие беренче балага – 2326 сум, икенче балага 4651 сум 99 тиен түләп барылды. Вакытлыча хезмәткә яраксызлык очрагына һәм бала тудыруга бәйле рәвештә, мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиеш булмаган (эшләмәүче) хатын-кызларга да баланы 1,5 яшькә кадәр тәрбияләү өчен бирелә торган айлык пособиеләренә индексация ясалды.

Шулай ук бала тугач та бер тапкыр бирелә торган пособие күләме дә артты. Ул узган ел 12405 сум 32 тиен булса, быелдан башлап 13087 сум 61 тиен тәшкил итәчәк. Шунысын белеп тору кирәк: әлеге индексация 2013 елның 1 гыйнварында һәм соңрак туган балаларга гына кагыла.

Йөкләнекнең иртә срогында (12 атнага кадәр) хатын-кызлар консультациясендә исәпкә баскан эшләүче булачак әниләргә бер тапкыр түләнә торган акчаның да күләме бераз артты. Быелдан башлап ул – 490 сум 79 тиен.

Бала тәрбияләгән өчен уртача хезмәт хакыннан (40 процент) чыгып билгеләнәчәк пособиегә исә индексация ясалмый.

Июнь аенда ярышлар «имтихан» тотачак

Казанда киләсе җәйнең июль аенда узачак Студентларның Бөтендөнья Универсиадасында спортчылар 351 бәрәмлек медаль өчен көч сынашачак.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

«Казан-2013» башкарма дирекциясенең баш консультанты Ранко Тепавчевич сөйләгәнчә, медальләр саны 2012 елда Лондонда булган Олимпия уеннарындагыдан 50 берәмлеккә күбрәк.

Татарстан башкаласындагы Универсиада Студентлар Спортының Халыкара Федерациясе (FISU) тарихында иң колачлысы буларак елъязмага теркәләчәк. Спортның 27 төреннән ярышларны берьюлы әле бер генә шәһәр дә үткәрмәгән. Җанатарларны һәм телевизион тапшырулар тамашачыларын исәпкә алып, уеннар көннәргә бертигез сандарак бүленгән. Казанның кайбер корылмалары спортның берничә төреннән уеннар оештыру мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, Спортның су төрләре сараенда йөзү, синхрон йөзү, суга сикерү бәйгесе планлаштырылса, Спортның ишү төрләре үзәгендә байдаркада һәм каноэда, академик ишү һәм ачык суда йөзү ярышлары булачак.

Спорт программасы – Универсиаданың йөрәге. Фәкать бәйгеләрне оештыруда гына да меңнән артык белгеч катнашачак. Кадрлар әзерләү дәвам итә. Алар соңыннан да ихтыяҗда торачаклар, чөнки алда Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты һәм Конфедерация Кубогы көтә.

Казандагы Универсиадада катнашу өчен АКШ, Япония һәм Кытайның рекордлы санда спортчылар җибәрергә җыенуы мәгълүм. Чит илләрдән 831 хөкемдар һәм рефери киләчәк, моның өстенә тагын 1500дән артык җирле хөкемдар эшләячәк. Узган ел Универсиада корылмаларында спортның 12 төреннән халыкара тест, ягъни ияләшү ярышлары үткәреп каралды. Генераль репетиция рәвешендә, июнь ае ахырында, спортның 19 төреннән берьюлы ярышлар оештырылачак. Аңа нәкъ Универсиаданың бер көнендәге ярышлардагы кебек 7-8 мең кеше җәлеп ителәчәк. Универсиада авылы, җәмәгать туклануы предприятиеләре, коммуникация, транспорт һәм башка тармаклар шулай ук чынбарлыктагыча сынау узачаклар. Гомумән, бөтен тырышлык һәм җаваплылык Универсиаданы югары дәрәҗәдә үткәрүгә юнәлдерелгән.

ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР

Мәсьәләне яңа мәчет хәл итсә генә

Җәйге терактлардан соң, Казанда гарәпчә язу белән аклы-каралы әләм күтәреп йөрүче кешеләр сәяси активлык күрсәтергә кереште. Алар башта, «мөселманнарны кулга алуны туктатырга» дигән шигарьләр күтәреп, мәйданнарга пикет-митинглар белән чыксалар, соңрак Гает бәйрәмнәрендә әлеге әләмнәр белән машиналарга утырып урам әйләнә башладылар. Инде бәйрәмнәр узды, тынычланганнардыр, дигән идем, баксаң, яңа ел алдыннан Казан-Яшел Үзән машина трассасында кабат әләмнәр җилфердәгән икән.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Болар әллә эшсезлектән интегә, әллә аларга тиешле игътибар җитми, аңламассың... «Аллаһ бер һәм Мөхәммәд аның илчесе» икәнен мөселман кешесе әләм җилфердәтмичә дә белә ләбаса! Бу сүзләр әләмдә түгел, йөрәктә булырга тиеш лә! Аннан соң Аллаһка тугрылыкны әләм күтәреп түгел, ә хәер-догада булып, изге гамәлләр кылып күрсәтү урынлырактыр инде ул.

Юк, әлеге егетләрнең йөрәкләренә бу сүзләр язылмагандыр диясем килми минем. Әнә бит, бу мәхәллә халкы мәчетләренә исемне дә «Әл-Ихлас» дип кушкан. Карап торышка үзләре дә бик ихлас күренәләр. Тик, ялгышу, акыл чуалуы да ихлас күңелдән булырга мөмкин икәнлеген онытмасак иде. Берәү дә ялгышам дип ялгышмый. Алар җәй көне мөселманнарны яклау митингын «Азатлык» татар яшьләре белән бергә үткәрергә килеште, әмма көне килеп җиткәч, шушы аклы-каралы әләмнән кала мәйданда башка әләмгә урын булмаячагын җиткерделәр, «Татарстан әләмен (дәүләт символикабызны. – **Ф.Г.**) күтәрергә ярамый», дип чакыра башладылар. Юл куйсаң, шәт, бөтен дөньясын аклы-каралыга әйләндереп бетерерләр иде. Ә бит күңелнең башка төсләрне дә, дөньяның матурлыгын һәм төрлелеген дә күрәсе килә... «Мәчет» дип аталучы, чүплек савыты янында урнашкан иске котельныйлары урынына, Декабристлар урамы буенча урнашкан микрорайонда яшәүче мөселманнарның мәнфәгатьләрен кайгыртып, хакимияттән зур, якты, җылы яңа мәчет дауласалар бер хәл иде. Кайчак кирәкмәгән сафсата белән шөгыльләнә бит алар. Имеш, «Исламда милләт юк!» икән. Ә ни өчен без шулай күптөрле дә, ни өчен Аллаһ Тәгалә Коръән-Кәримдә: «Мин сезне бер-берегезне танып белсен өчен ир белән хатын итеп, кавем-кабиләләр итеп яраттым. Миңа иң якын булучыгыз – иң тәкъвагыз», – дигән соң? Аллаһ безне шулай яраткан икән, шулай саклану да безнең бурычларның берсе, Аллаһның нигъмәте бит юкса!

Әлеге төркем мөселманнар авызыннан: «Мөхәммәд Пәйгамбәр милләт өчен үлүне хәрам дип әйткән», – ише сүзләр дә ишетергә туры килгәләде. Ә кем соң әле милләт өчен үләргә җыена? Малмөлкәт өчен, яраткан кешесе өчен үләргә әзер булучылар бардыр, әмма «мин милләтем өчен җанымны бирергә әзер» диючеләр күбрәк купшы сүз сөйләү белән генә мавыга кебек. Шунысы хак: Адәм баласы, нинди генә гамәл кылса да, моны Аллаһ ризалыгы өчен эшләргә тиеш. Ә нигә мин Аллаһ ризалыгы өчен үз милләтемә хезмәт итмәскә, үз милләтемне, туган җиремнең, дәүләтемнең символикасын яратмаска тиеш ди әле?! Минемчә, милләтне саклау юлында көрәшү ул шулай ук Аллаһ ризалыгы өчен эшләнелә торган гамәл. Ә дәүләтчелегебез символы булган Татарстан әләменә каныгу нигә кирәк? Аллаһның хакыйкате, Адәм балаларына җибәргән дине гел бер. Ул да булса, Аңа гыйбадәт кылу, изгелекләр эшләү, яманлыктан тыелу. Ләкин Адәм балалары гына бу кагыйдәләрне, Аллаһның ирештергән сүзләрен гел үзләренчә аңлый, һәркем үзенчә кабул итә. Ә без бүген күпмилләтле, күпдинле дәүләттә яшибез. Берәүләрнең көен көйләп, башкаларны кыерсытырга хакыбыз юк безнең. Шунысы хак: котельный ул котельный, ә мәчет ул мәчет булырга тиеш. «Әл-Ихлас» мәчете, ни кызганыч, мәхәллә халкын канәгатьләндерерлек хәлдә түгел. Тирә-юнендәге чисталыкның торышына Роспотреб белгечләре дә беркетмә төзегәннәр. Декабристлар урамындагы микрорайонга өр-яңа, зур мәчет кирәк. Анда динебезне генә түгел, милләтебезне дә кайгырта белүче имамнар эшләсә, әйләнә-тирәдәге мөселманнар өчен күпкә тынычрак һәм хәерлерәк булыр иде.

Өндәү файдасы

Рафаэль САЛЬМУШЕВ

Без өлкәннәр: «Хәзерге яшьләр тәрбиясез, урын да бирмиләр», – дип ачуланырга яратабыз. Юк, җәмәгать, үзгәрде яшьләр. Автобуска өлкәннәр килеп керүгә, сикереп торып: «Утырыгыз», – дип урын бирә башладылар. Бу үзгәрешкә нәрсә сәбәпче булды икән?!

Хәзер күп автобусларда тукталышларны радио челтәреннән русча-татарча әйтәләр, шул ук вакытта өлкәннәргә, балалы хатыннарга урын бирү турында да искә төшерәләр. Бу турыда быел хәтта автобус салоннарында да киңәш-плакатлар эленгән иде. Мондый җайланмаларны шәһәрнең бөтен төр җәмәгатьчелек транспортына урнаштырырга кирәк. Радио-автомат аша тукталышларны гына әйтү бер хәл, пассажирларга шәһәрнең чисталыгы турында мөрәҗәгать итүләре бигрәк тә куандыра.

Чын татар җыры кирәк

Әхмәтназыйф ГАТАУЛЛИН

Мин – Оренбург өлкәсендә туган кеше. Күп еллар буе (30 ел) армия сафларында хезмәт иткәннән соң Казанга кайтуыма 30 ел тулды. Гомер буе татар әдәбиятына, мәдәниятенә мохтаҗ булып яшәгәч, Татарстан халкы тормышына кушылып, үз тормышымны кордым. Музыкант, җырчы булмасам да, башкаручыларны бик яратып тыңлыйм, әмма иң яхшы җырчылар, шагыйрьләр китеп бара, шунысы кызганыч. Яшьләр, үзләренчәгә борып, күбесенчә такмак әйтеп яңа җырлар чыгара башлады, шуңа бераз эчем поша. Алар арасында да бик матур җырлаучылар бар барын. Бу хатымда мин Зәйнәб Фәрхетдинова турында бер-ике сүз әйтеп китәргә теләгән идем. Концертын бик яраттым, аңа зур рәхмәт әйтәсем килә. Бигрәк тә татар халык җырларын бик оста җырлап күңелне ачты ул. Газета аша аңа бер-ике теләгемне дә җиткерер идем. Киләчәк программаларына чын татар җырларын күбрәк кертсә иде.

Мәсәлән, «Казан сөлгесе», «Салкын чишмә», «Зәңгәр күлмәк», «Рамай», «Бөдрә тал», «Сары каеш», «Уракчы кыз» кебек җырларны аның башкаруында ишетсәк, бездәй олы кешеләр бик бәхетле булыр иде.

Конкурсный управляющий ООО «Уют» (ИНН 1659057970, ОГРН 1051637030686), 420054, г. Казань, ул.Промысловая, 5, Юсупов Р.С. (ИНН 020202485576, 452122, РБ, Алынеевский р-н, с. Раевский, ул. Кирова 249-в, тел. 89174230259, e-mail: yusrastem@mail.ru) объявляет 19.02.2013 г. в 11.00 ч. публичные электронные торги на электронной площадке Сбербанк АСТ по продаже имущества состоящего

Лот № 1: Нежилое помещение №1000, адрес: г. Казань, ул. Промысловая, д. 5, инвентарный номер 50П.2-11468/-40, S=13,20 кв. м., Нежилое помещение № 1001, адрес: г. Казань, ул. Промысловая, д. 5, инвентарный номер 50П.2-11468/1-54а, S=16,10 кв. м., Нежилое помещение № 1003, адрес: г. Казань, ул. Промысловая, д. 5, инвентарный номер 50П.2-11468/1-61, S=7,4 кв. м., Нежилое помещение № 1007, адрес: г. Казань, ул. Промысловая, д. 5, инвентарный номер 50П.2-11468/1-41, S=19,90 кв. м., начальная цена продажи - 880 000 руб. (Восемьсот восемьдесят тысяч руб. 00 коп.)

Лот № 2: Нежилое помещение № 1008, адрес: г. Казань, ул. Промысловая, д. 5, инвентарный номер 50П.2-11468/П-14, S=20,40 кв. м. (подвал), начальная цена продажи - 88 000 руб. (Восемьдесят восемь тысяч руб. 00 коп.) Шаг аукциона 5 % от начальной цены продажи, а именно лот № 1 - 44 000 (Сорок четыре тысячи) рублей, лот № 2-4 400 (Четыре тысячи четыреста) рублей.

Задаток в размере 8 000 руб. по каждому лоту вносится в счет обеспечения оплаты приобретаемого на торгах имущества на р/с: 40702810900010004758 в АКБ «Энергобанк» г. Казань, к/с 30101810300000000770, БИК 049205770, ИНН 1659057970. Срок внесения задатка - в течение пяти дней с момента публикации объявления о торгах. Документы к участию: Заявка, документ о задатке, действительная на день представления заявки на участие в торгах выписка из ЕГРЮЛ/ЕГРИП, выданная не позднее 15 дней до ее представления, либо их нотариально заверенные копии, копии документов, удостоверяющих личность, документ, подтверждающий полномочия лица на осуществление действий от имени заявителя. Победитель - лицо, предложившее наибольшую цену за лот. Продавец - ООО «Уют». Подписание протокола о результатах торгов - в день его проведения; Договор купли-продажи - в течение 5 дней с даты подведения итогов. Полная оплата - в течение 30 дней с даты заключения договора купли-продажи. Ознакомление с документами, имуществом и прием заявок с 10 ч. 00м. до 16 ч. 00м. ежедневно, со дня публикации в течение 25 рабочих дней, www.bankruptcy.sberbank-ast.ru. Победителю торгов, в случае отказа или уклонения от подписания договора купли-продажи Имущества Должника в течение 5 дней с момента получения проекта договора, Задаток не возвращается, договор считается незаключенным. Лицам, проигравшим торги, уплаченный задаток возвращается в течение 5 дней, с момента подведения итогов торгов.

Гаиләм тарихы — ил тарихының чагылышы

Кешелек дөньясы яралганнан бирле нинди генә вакыйгалар булмаган да, кешеләрнең башыннан нинди генә хәлләр кичмәгән. Шуларның иң зурысы, әле бүген дә фаҗигасе күңелләрдә тирән эз калдырганы – Бөек Ватан сугышы. Бу сугыш зыян салмаган гаилә юктыр... Безнең гаиләгә дә кагылган ул афәт. Әниемнең әтисе Мингариф бабам да, әтиемнең әтисе Хәйдәр бабам да сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китәләр, батырлыклары өчен, бик күп орден һәм медальләр белән бүләкләнәләр.

Резеда КАЮМОВА,
Арча районының Түбән Аты мәктәбе укучысы

1944 елның ахырында, каты яраланып, госпитальгә эләгәләр. Шуннан соң снаряд ярчыкларын тәннәрендә саклап, туган якларына кайтып егылалар. Дәү әниемнең (ул Газизә исемле иде, кызганыч, 1 ел элек 96 яшендә вафат булды) сөйләве буенча, ул ярчыкларны соңрак нинди авырлык белән алуларын белдем. Әнием дә үз әтисенең нәкъ шулай тилмерүен сөйләде.

Бабаларым сугыш кырында фашистларга каршы көрәшсә, ике дәү әнием дә, бөтен көчләрен куеп, тылда эшләгәннәр. Газизә дәү әнием цех мөдире, партоешма секретаре вазифаларын башкарса, Миңлегөл дәү әнием кырчылык бригадиры булган. Икесе дә авыл советы, район советы депутаты, стахановчы булганнар. Сугыштан соң икесенең дә алтышар баласы туган. Ике яктагы дәү әти һәм дәү әниләрем дә тәрбияле, тырыш балалар үстергәннәр. Алар арасында укытучылар, хисапчылар, төзүчеләр, терлекчеләр һәм башка һөнәр ияләре бар.

Мингариф дәү әтиемнең бабасы салдырган кибет әле дә исән. Төзелүенә берничә гасыр үтсә дә, ул авыл уртасында тарихи һәйкәл булып тора, әле дә кибет вазифасын башкара. Ә дәү бабам Хәмидулла (аны Кәмәй бай дип йөрткәннәр) салдырган мәчетне мәктәпкә әйләндергәннәр. Әнием һәм аның абый-апалары шунда укыган.

Ә инде әтиемнең әтисе Хәйдәр бабам салган йортлар, ул эшләгән тегермән авылыбызда әле дә саклана. Кулыннан килмәгән эше булмаган шул Хәйдәр бабамның. Әтиләре Каюм бабай үлгәндә, дәү әтием белән Габделәхәт абый бик кечкенә булалар. Озакламый әнисез дә калалар. Ярый әле дәү әтием – 8, Габделәхәт абыем 7 яшькә җиткәнче, әбиләре Миңлекамал исән була. Әмма ул да кыска гомерле була шул. Әбиләре исән вакытта ятимлекне әллә ни аңлап бетермәгән балалар тормыш авырлыклары алдында япа-ялгыз калалар. Тамаклары ипигә туймаса да, ялгыш юлга басмыйлар: кечкенәдән эшкә өйрәнеп, бер-берсенә терәк булып, авырлыкларны җиңеп чыгалар. Ничек югалып калмады икән дәү әтием?! Моның сере аның олы йөрәкле булуындадыр, мөгаен. Газизә әбиемә өйләнгәч тә, аның әнисен һәм бөтенләй зәгыйфь Кәшифә апасын да ташламый дәү әтием, аларны үз тәрбиясенә ала.

Ә Габделәхәт абый тормыш корып та өлгерә алмый: сугышка китә һәм хәбәрсез югала. Озак еллар эзләтсәк тә, каберенең кайда икәнлеген белми идек. Шөкер, быел әтием аны эзләтеп таптыра алды. Орёл өлкәсенең Людиново районындагы Полики авылында җирләнгән икән. Әтием җәйгә аның каберен зиярәт кылырга уйлап тора.

Бүген дә илдә барган вакыйгалар гаиләләргә, аерым кешеләрнең язмышына кагылмый калмый. Әфганстан һәм Чечняларның кайтавазы бүген дә күңелләрдә. Өстәвенә мәктәбебездә укучы Зәринә исемле кызның әтисе, Әфганстаннан кайтып берничә ел узуга, вафат булды. Зәринә кеп-кечкенә көе әтисез калды, «әтием» дип әйтергә тилмереп үсте. XXI һәм аннан соңгы гасырлар тынычлык-татулык һәм үсеш гасырлары булып тарихка керсен иде!

«АК БАРС» көрәш сарае

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

УНИВЕРСИАДАЛЫ КАЗАН

Казанда быелның 5-17 июль көннәрендә студентларның XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы узачак. Дөньяның 170 иленнән 10 меңгә якын спортчы көч сынашачак. Ярышлар һәм күнегүләр өчен 64 корылма файдаланылачак. 2012 елның июнь аена 27 корылма төзелгән һәм кулланууда иде инде, тагын 30 корылма сафка бастырылачак. Универсиада авылы, Халыкара мәгълүмат үзәге – спорт корылмалары исемлегенә кермәүче төзелешләр. «Ак Барс» көрәш сарае – Универсиадага әзерлек кысаларында төзелгән күптөрле эшчәнлек юнәлешле корылма. Казансу елгасы буена «Миллениум» күпере янәшәсенә урнашкан заманча архитектуралы бина халыкара дәрәҗәдә җиһазланган. Монда 4 күнегүләр залы, душ кабиналы киенү-чишенү бүлемнәре, сауналы һәм бассейнлы ял итеп алу бүлмәләре бар. «Ак Барс» көрәш сарае фехтование буенча Европа чемпионатын, тхэквондо буенча Европа турнирын кабул итәргә дә өлгерде. Бирелә Казан мэры Кубогына милли көрәш чемпионатлары да үткәрелә.

Корылма 2009 елның октябреннән эшли башлады. «Ак Барс» көрәш сарае беренче көннәреннән үк һәнәри спортчыларда һәм һәвәскәрләрдә мәхәббәт уялады.

Безнекеләр йөк зачетында — җиңүче

Бу көннәрдә Дакарда Africa Race раллие төгәлләнде. Безнең «КАМАЗ-Мастер» командасының экипажы йөк зачеты буенча тәүге җиңүен яулады. Моннан тыш, алар «внедорожниклар» арасында узган күмәк зачетта да икенче урынны алды. Беренчелеккә исә Луи Шлессер ия булды. Яр Чаллы «КАМАЗ-Мастер» командасы экипажының Антон Шибалов, Евгений Яковлев һәм Дмитрий Сотников составында Africa Race ярышында шулай ук тәүге катнашуы.

СПОРТ

Команданы рухландырырга «Дакар» раллиенда биш мәртәбә чемпион калган, «КАМАЗ-Мастер»га нигез салган кеше – Владимир Чагин экипажының штурманы Семен Якубов та барган. Семен 2009 елдан «Ефәк юлы» халыкара раллиен башлап җибәреп, аңа «Дакар» сериясе статусы яулаган шәхес.

Ә «Дакар-2013» трансконтиненталь раллиеның бишенче этабында безнең 501 нче санлы экипажыбыз финишка икенче булып килде. Әлеге экипажны Эдуард Николаев, Сергей Савостин һәм Владимир Рыбаков тәшкил итә. Беренче урынны исә Ханса Стейси җитәкчелегендәге голландиялеләр яулады. Алар безнекеләрдән 1 минут 53 секундка алданрак килә. Айрат Мәрдиев, Айдар Беляев һәм Антон Мирный составындагы 505 нче экипажыбызга исә дүртенче урын, 510 нчы экипаж булган Андрей Каргинов, Андрей Мокеев һәм Игорь Девяткиннарга алтынчы урын гына эләгә. Илгизәр Мәрдиев җитәкчелегендәге техник ярдәм экипажы, 14 минут та 13 секунд соңарып, 11енче булып килә.

КӨЛГӘНГӘ – КӨЛКЕ

Татар эшмәкәре бик әһәмиятле очрашуга бара икән. Ашыга, кабалана, нервлана, җитмәсә машина куяр урын юк. Инде нишләргә дип торганда, Аллаһы искә төшереп күккә бага бу:

– Йа Раббым! Бүгеннән үк эчүемне, гүләйт итүемне ташлыйм, мәчеткә җомга намазына йөри башлыйм – машина куяр урын гына табып бир! Шулчак янәшәдә генә бер урын бушый. Эшмәкәр янә күккә карап:

– Ярар, кирәкми инде, таптым!

* * *

Малаеның рәсемнәрен карап утыргач, әтисе:

– Улым, син нигә мине сары чәчле итеп ясадың?

– Миндә пелөш буявы юк иде...

* * *

Узган ел Кыш бабайдан мине Жерар Депардьеның ватандашы итеп ясавын үтенгән идем. Картлач сүзләрнең мәгънәсен бозып аңлар дип кем уйлаган?!

СКАНВОРД



Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН төзеде

28 декабрь санында чыккан сканворд җаваплары:
Горизонталь буенча: өчпочмак, су, онча, кояш, атом, рада, әбрәкәй, үрмәкүч, ташлык.
Вертикаль буенча: өзгәләнү, рам, кок, мәгарә, тай, комод, Марат, Сак, соя, шашлык.

КИҢӘШ-ТАБЫШ

Башыңны капла да... сула!

Салкын тигән чакта парлы ингаляцияләр ярдәмгә килүен күпләр белә. Ә менә аны ничек дөрес итеп ясарга икәнлеген белмәүчеләр дә бардыр әле. Грипп котырган чорда хәлләрегезне җиңеләйтү максатыннан ингаляцияләр ясарга уйласагыз, түбәндәгеләрне белеп тору хәерле.

Парлы ингаляцияләрне тән температурасы 37,5 градустан артканда ясарга ярамый. Шулай ук гипертония, йөрәк авыруларыннан интегүчеләргә дә бу тыелган. Теләсә кайсы ингаляциянең 15 минуттан да артырга тиеш түгеллеген дә белеп торыгыз. Балалар өчен аның вакыты – 5 минут. Көненә 1-2 тапкырдан да артык ясарга ярамый. Балаларга ингаляция 2-3 яшьлек чакларыннан алып һәм олы кеше күзәтүе астында гына ясыйлар. Шифасы күбрәк тисен, дип, кайнап утыручы су өстенә үк иелеп ингаляция ясау катгый тыела. Аны су кайнап чыгып 5 минут үткәннән соң (балалар өчен – су кайнап чыкканнан соң 10 минуттан) гына ясарга кирәк. Өске тын юлларын дәвалау максатыннан, лаванда, зәңгәр мәтрүшкә, ромашка, шалфей һәм үги ана яфрагы төнәтмәләреннән файдаланалар. Берничә төрле үләне бергә кушкан очракта файдасы күбрәк була. Төнәтмә ясау өчен 1 аш кашыгы үлән чималын 250 мл су белән кушып төнәтергә кирәк. Төрле эфир майларын һәм төнәтмәләрне ингаляция ясар өчен кайнатырга куйган суга башта ук салып җибәрергә кирәк. Аларны дөбердәп кайнап утыручы суга соңыннан гына салып җибәрү дөрес түгел.

Салкын тиеп, тамак бизләре шешкәндә тамакны еш чайкау да хәлне җиңеләйтү чарасына керә. Ромашка, шалфей, бөтнек һәм тырнак гөл (ноготки) төнәтмәләре – сынап карлган чаралар. Әле тагын суган кабыгыннан да файдаланырга була. 3 чәй кашыгы суган кабыгын кайнап чыккан ярты литр суга салып, тагын берничә минут кайнатып алалар һәм 4 сәгатьләп төнәтәләр. Соңыннан, сөзеп, шуның белән тамакны чайкыйлар.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Без бергә булганда гына көчле!

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: «ТАТМЕДИА» ААҖ www.shahrikazan.com Реклама хезмәте телефоны: (843) 562-50-12

Шәһри КАЗАН

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры – баш мөхәррир Мансур Газизҗан улы МОРТАЗИН

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: 420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Http://shahrikazan.com
E-Mail: shahri-kazan@tatmedia.com
ТЕЛЕФОННАР: 562-50-12 – кабул итү бүлмәсе, 562-50-07 (факс), 562-63-90 – бухгалтерия, 562-50-03 – хатлар бүлеге.
НӘШРИЯТ: «ТАТМЕДИА» ААҖ 420097, Казан, Академия ур., 2

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды.

БАСМАХАНӘ: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт. «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

Тираж сертификацияләнгән.
Тираж – 3404 данә

Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
© Газетада басылган язмаларны файдаланганда, шулай ук өзекләр китергәндә «ШК»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга
Заказ 29463
ИНДЕКСЛАР:
54126 (3 тапкыр чыга),
16076 (пәнҗешәмбе саны)
54207 (оешмалар өчен)
Сатудагы бәясе ирекле
12+